**Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы**
**Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы**
**КАРАРЫ**

Азнакай шәһәре № 50-11 26 октябрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге 111-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре бюджет процессы турында» карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет процессы турында» Положениегә үзгәрешләр кертү хакында (23.07.2009 №140-37, 11.12. 2009 №148-40, 11.11.2010 №7-2, 20.04.2011 №27-7, 22.10.2013 №103-31, 12.08.2014 №135-40, 21.10.2015 №9-2, 09.11.2017 №67-19, 20.08.2019 №142-35, 22.10.2019 №147-36, 12.03.2020 №162-41, 16.06.2020 №174-43, 14.12.2020 №17-3, 26.08.2021 №66-9 карарлра редакциясендә)

2021 елның 1 июлендәге 244-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясе Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Россия Федерациясе Бюджет кодексының 242.17 статьясындагы 4 пунктының гамәлдә булуын туктатып тору турында» Федераль закон нигезендә,

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәр Советы

**карар итте**

1. Татарстан Республикасы Азнакай шәһәр Советының 2008 елның 25 декабрендәге 111-30 номерлы «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының Азнакай шәһәре бюджет процессы турында» карары белән расланган, «Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының бюджет процессы турында» Положениегә үзгәрешләр кертү хакында (23.07.2009 №140-37, 11.12. 2009 №148-40, 11.11.2010 №7-2, 20.04.2011 №27-7, 22.10.2013 №103-31, 12.08.2014 №135-40, 21.10.2015 №9-2, 09.11.2017 №67-19, 20.08.2019 №142-35,

22.10.2019 №147-36, 12.03.2020 №162-41, 16.06.2020 №174-43, 14.12.2020 №17-3, 26.08.2021 №66-9 карарлра редакциясендә)

1) 9 статьяның 10 өлешендәге өченче абзацына «бюджетның бердәм счетында калдыклар белән идарә итү операцияләреннән тыш»сүзләрен өстәргә;

2) 14.12 статьяның 27 пунктына түбәндәге эчтәлекле тәкъдим өстәргә: "кредит (заем, облигациядән тыш) буенча принципал йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган муниципаль гарантия кредит килешүендә (займ килешүендә) һәм (яисә) күрсәтелгән муниципаль гарантияне бирү турындагы килешүдә кредитор (заемчы) йөкләмәләрен үз ягыннан күрсәтелгән кредит (займ) акчаларыннан максатчан файдалануны тикшереп тору шарты белән бирелә.».

2. Әлеге карарның 1 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

3. Әлеге карарны "Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында" түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча урнаштырырга: http://aznakayevo.tatarstan.ru.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Советының бюджет, финанслар, салымнар һәм икътисад буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Рәис М. З. Шәйдуллин